«РАСЛЫЙМ»
«Сәләт» ТРЯИФ
генераль директоры

Җ. Ш. Сөләйманов
«17» апрель, 2020 ел

**Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан Татар Википедиясендә Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр турында мәкаләләр язу марафоны үткәрү турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан Татар Википедиясендә Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр турында мәкаләләр язу марафоны (алга таба – Марафон) Татарстан Республикасы «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды (алга таба – «Сәләт» ТРЯИФ), «Сәләт» яшьләр үзәге дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «Сәләт» ЯҮ ДБУ) һәм Сәләт клубы тарафыннан Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәмендә оештырыла.

1.2 Марафон үткәрүнең төп мәйданчыгы итеп, күптелле ирекле онлайн энциклопедия Википедиянең татар телле версиясе кулланыла.

## 2. Марафонның максаты һәм бурычлары

2.1 Марафонның максаты – Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләрне искә алу һәм Интернет челтәрендә алар турында татар телендә ышанычлы мәгълүмати контентны мәкаләләр рәвешендә урнаштыру.

2.2. Марафонның бурычлары:

- халык арасында, беренче чиратта - яшьләрдә, Бөек Ватан сугышында катнашкан шәхесләр турында тарихи хәтер дәрәҗәсен күтәрү;
- татар телендә иң зур ирекле онлайн-энциклопедиядә – Татар Википедиясендә бу шәхесләр белән бәйле ачык мәгълүматны арттыру;
- үз халкының һәм туган төбәгенең тарихы белән кызыксынучы актив катнашучыларга ярдәм итү.

## 3. Марафонда катнашучылар

3.1 Марафонда Татар Википедиясендә (tt.wikipedia.org) теркәлгән кулланучылар, ягъни анда теркәлгән 14 яшьтән 30 яшенәчә булган яшьүсмерләр һәм яшьләр катнаша ала.

3.2 Катнашу өчен номинацияләр саны чикләнмәгән.

## 4. Марафонның үткәрелү шартлары, тәртибе һәм үткәрү вакыты

4.1 Марафон өч этапта үткәрелә:

1 этап – «Марафонга старт бирелү» - **23.04.2020 ел.**

Татар Википедиясендә мәкаләләр язу һәм бастырып чыгару.

2 этап – «Мәкаләләрне тикшерү». **20-25.05.2020 ел.**

Әлеге этапта жюри әгъзалары барлык язылган мәкаләләрне тикшереп, җиңүчеләр исемлеген төзи.

3 этап – «Җиңүчеләрне бүләкләү».

Бүләкләү IX Халыкара «Сәләт» яшьләр уку-укыту форумы кысаларында үткәреләчәк. Җиңүчеләр бүләкләүгә кимендә бер ай кала игълан ителәчәкләр.

4.2. Тантананы үткәрү датасын һәм вакытын Марафонның Оештыру комитеты аерым хәбәр итәчәк. Оештыру комитеты Марафон этапларының даталарын көтелмәгән хәлләр булган очракта үзгәртергә хокуклы.

## 5. Марафонның номинацияләре һәм бәяләү критерийлары

5.1 Марафон «Иң яхшы мөхәррир» һәм «Иң яхшы автор» номинацияләрендә үтәчәк. Марафонда катнашу өчен Татар Википедиясендә түбәндәге төркемнәргә кергән Бөек Ватан сугышы фронтовиклары турында мәкаләгә төзәтмәләр кертергә яки яңа мәкалә язырга кирәк:

- Советлар Союзы каһарманнары;
- «Җиңү» ордены ияләре;
- Кызыл Байрак ордены ияләре;
- I, II, III дәрәҗә Суворорв ордены ияләре;
- I, II, III дәрәҗә Кутузов ордены ияләре;
- Александра Невский ордены ияләре;
- I, II дәрәҗә Ватан сугышы ордены ияләре;
- Кызыл Йолдыз ордены ияләре;
- «Шәхси батырык өчен» ордены ияләре;
- «Батырлык өчен» медале ияләре;
- «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале ияләре;
- Фронтта яшь килеш вафат булганнар (30-дан яшьрәкләр).

5.2 Номинацияләр:

**«Иң яхшы автор» номинациясе**

Номинациядә катнашу өчен мәҗбүри шартлар:

- әлеге номинациядә катнашучылар Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм алда санап үтелгән төркемнәрнең кимендә берсенә кергән шәхесләр турында яңа мәкаләләр язалар.

  Бәяләү критерийлары:

  - Язылган мәглүматның күләме һәм тирәнлеге;
  - Медиа-файлларның өстәлгән булуы;
  - Татар Википедиясе кагыйдәләре буенча мәкаләләрне рәсмиләштерү;
  - Мәгълүмат чыганаклары булу;
  - Мәкаләдә татар теле дәрәҗәсе.

**«Иң яхшы мөхәррир» номинациясе**

Номинациядә катнашу өчен мәҗбүри шартлар:

- әлеге номинациядә катнашучылар Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм алда санап үтелгән төркемнәрнең кимендә берсенә кергән шәхесләр турындагы булган мәкаләләрне төзәтәләр.

Бәяләү критерийлары:

- Язылган мәглүматның күләме һәм тирәнлеге;
- Медиа-файлларның өстәлгән булуы;
- Татар Википедиясе кагыйдәләре буенча мәкаләләрне рәсмиләштерү;
- Мәгълүмат чыганаклары булу;
- Мәкаләдә татар теле дәрәҗәсе.

## 6. Марафонны Оештыру комитеты

6.1 Оештыру комитеты Сәләт клубы активистлары, «Сәләт ВикиМәктәбе» проектының оештыру командасы, шулай ук Викимедиа халыкара берләшмәсе вәкилләре арасыннан Марафонны әзерләү һәм уздыру өчен төзелә.

6.2 Оештыру комитеты:

- Марафонга әзерлекне оештырыра;
- Марафонның әзерлек һәм үткәрү этапларында административ тәэмин итүне гамәлгә ашыра;
- Марафонның барлык этапларын үткәрү программасын эшли һәм раслый, үткәрү вакытын һәм урынын билгели;
- Жюри составын эзләү һәм раслауны гамәлгә ашыра.

## 7. Марафонның эксперт советы

7.1 «Мәкаләләрне тикшерү» этабын үткәрү һәм бәяләү өчен эксперт советы төзелә. Марафонның эксперт советы составын Марафонның Оештыру комитеты раслый.

7.2 Эксперт советы составына Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе җәмәгатьчелекләре һәм иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре һәм фәнни җәмәгатьчелек әгъзалары керә.

7.3 Марафонның эксперт советы Марафонның беренче этабында тәкъдим ителгән мәкаләләргә тикшерү үткәрә һәм җиңүчеләр турында карар кабул итә.

## 8. Гаризаларга таләпләр

8.1 Катнашучының гаризасы ике мәйданчыкта теркәлергә тиеш: Татар Википедиясендә Марафон битендә тутырылган таблицада һәм selet.biz сайтында тутырылган формада. Тулырак инструкция белән түбәндәге сылтама буенча танышырга мөмкин:

## 9. Гаризалар бирү тәртибе

9.1 Марафонга гаризалар бирү – **2020 елның 20 маенда 23:59 (UTC+4)** сәгатьтә тәмамланачак.

Белешмәләр өчен телефон: 7-987-405-18-84 – Хәбил Сахабиев, «Сәләт ВикиМәктәбе» проекты җитәкчесе.

9.2 Әлеге нигезләмә таләпләренә туры килми торган гаризалар белән катнашу рөхсәт ителми.

9.3 Гаризалар җитәрлек булмаган очракта, Оештыру комитеты гаризаларны кабул итү вакытын озайтырга, шулай ук Марафон номинацияләренең берәрсен үткәрелмәгән дип танырга хокуклы.

## 10. Марафонга йомгак ясау

10.1. Марафонда катнашучылар электрон сертификатлар белән бүләкләнә.

10.2. Марафон нәтиҗәләре буенча иң күп балл җыйган 6 җиңүче билгеләнә. Җиңүчеләрнең исемнәре бүләкләү тантанасында игълан ителәчәк.

10.3. Марафонда җиңүчеләр Марафон брендтагы повербанк, истәлекле бүләкләр һәм дипломнар белән бүләкләнә.

10.4. Марафон нәтиҗәләре басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән Татар Википедиясе порталында да игълан ителә.